«РАСЛЫЙМ»
Татарстан Республикасы
мәгариф һәм фән министры
_____ И.Г.Һадиуллин
«19» ноября 2025 нче ел

Туган телдә белем бирү мәктәпләре укучылары өчен 2026 нчы елда туган (татар) әдәбияттан дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыру өчен әзерлек дәрәҗәсенә куелган таләпләр һәм эчтәлек элементларының кодификаторы

разработан федеральным государственным автономным образовательным учреждением высшего профессионального образования
«КАЗАНСКИЙ (ПРИВОЛЖСКИЙ) ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ»

подготовлен государственным бюджетным учреждением
«РЕСПУБЛИКАНСКИЙ ЦЕНТР МОНИТОРИНГА КАЧЕСТВА ОБРАЗОВАНИЯ»

утвержден МИНИСТЕРСТВОМ ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Татар әдәбиятыннан әзерлек дәрәҗәсенә куелган таләпләр һәм эчтәлек элементларының кодификаторы (алга таба - Кодификатор) – 2026 нчы елгы дәүләт йомгаклау аттестациясе эшенә контроль бәяләү материаллары төзү өчен дәүләт йомгаклау аттестациясе эшенең КБМ эчтәлеген билгеләүче документларның берсе.

Кодификаторда Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән дәреслекләргә, үрнәк белем бирү программасына кертелмәгән әзерлек дәрәҗәсе таләпләре чагылыш тапмый.

Бу документ татар әдәбиятыннан дәүләт йомгаклау аттестациясе эшен төзү өчен нигез булып тора, шуңа да уку материалын гомумиләштерү һәм системалаштыру принципларыннан гыйбарәт.

I БҮЛЕК. Татар әдәбиятыннан дәүләт йомгаклау аттестациясе эшендә тикшерелә торган теоретик база һәм әсәрләр исемлеге

Бүлек коды	Контроль бәяләү материалының коды	Контроль бәяләү материалларына нигезләнеп бәяләнүче берәмлекләрнең эчтәлеге
1	***Әдәбият теориясеннән һәм тарихыннан белешмә***	
	1.1	Сүз сәнгате буларак матур әдәбият.
	1.2	Фольклор. Фольклор жанрлары.
	1.3	Әдәби образ.
	1.4	Эчтәлек һәм форма.
	1.5	Әдәби төрләр: проза (эпик төр), лирика, драма; төрара формалардан лиро-эпика. Әдәби жанрлар: хикәя, повесть, роман; лирик шигырь, мәдхия, мәрсия; поэма, баллада; комедия, трагедия, драма.
	1.6	Тема. Проблема. Идея. Конфликт. Сюжет һәм сюжет элементлары: экспозиция, төенләнеш, кульминация, чишелеш, эпилог. Сюжеттан тыш элементлар. Композиция. Образлар системасы. Образларның төрләре. Персонаж. Характер. Тип. Автор образы. Лирик герой. Сурәтләнгән дөнья (портрет, пейзаж, урын-вакыт бирелеше). Геройның сөйләменә характеристика: диалог, монолог.
	1.7	Деталь. Символ.
	1.8	Психологизм.
	1.9	Әдәби әсәрнең теле. Әдәби әсәрдә тел-сурәтләү чаралары: лексик чаралар (синоним, омоним, антоним, фразеологизм һ.б.), фоник чаралар (аллитерация, ассонанс һ.б.), стилистик чаралар (инверсия, кабатлау, антитеза һ.б.), троплар

Бүлек коды	Контроль бәяләү материалының коды	Контроль бәяләү материалларына нигезләнеп бәяләнүче берәмлекләрнең эчтәлеге
		(чагыштыру, метафора, метонимия, аллегория, эпитет, сынландыру һ.б.).
	1.10	Шигырь төзелеше системалары: гаруз, силлабик. Ритм. Рифма. Строфа.
2	***Урта гасыр татар әдәбиятыннан***	
	2.1	Кол Гали. “Кыйссаи-Йосыф” поэмасы.
	2.2	“Идегәй дастаны”.
	2.3	С.Сараи. “Сөһәйл вә Гөлдерсен” поэмасы.
	2.4	Мөхәммәдьяр. “Төхфәи мәрдан” поэмасы.
3	***XIX гасыр әдәбиятыннан***	
	3.1	Г.Кандалый. “Сәхибҗәмал” поэмасы.
	3.2	К.Насыйри. “Әбугалисина кыйссасы”.
	3.3	М.Акъегет. “Хисаметдин менла” романы.
	3.4	З.Бигиев. “Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә” романы.
4	***XX йөз татар әдәбиятыннан***	
	4.1	Ф.Әмирхан. “Хәят” повесте, “Бер хәрабәдә” хикәясе.
	4.2	Ш.Камал. “Акчарлаклар” повесте, “Буранда” хикәясе.
	4.3	Г.Рәхим. “Яз әкиятләре” хикәясе.
	4.4	Н.Думави. “Яшь ана” хикәясе.
	4.5	Г.Тукай. “Пар ат”, “Ана догасы”, “Милләткә”, “Өзелгән өмид”, “Милли моңнар”, “Шагыйрь”, “Театр”, “Туган авыл”, “Җәйге таң хатирәсе”, “Кыйтга”, “Көзге җилләр” шигырьләре.
	4.6	Дәрдемәнд. “Кораб”, “Видагъ”, “Без” шигырьләре.
	4.7	С.Рәмиев. “Авыл” шигыре.
	4.8	Г.Ибраһимов. “Алмачуар” хикәясе.
	4.9	Г.Камал. “Беренче театр” пьесасы.

Бүлек коды	Контроль бәяләү материалының коды	Контроль бәяләү материалларына нигезләнеп бәяләнүче берәмлекләрнең эчтәлеге
	4.10	М.Фәйзи. “Галиябану” пьесасы.
	4.11	Һ.Такташ. “Ак чәчәкләр” шигыре, “Алсу”, “Мокамай” поэмалары.
	4.12	К.Тинчурин. “Сүнгән йолдызлар” драмасы.
	4.13	Г.Кутуй. “Тапшырылмаган хатлар” повесте, “Сагыну” нәсере.
	4.14	Г.Исхакый. “Җан Баевич” комедиясе.
	4.15	М.Җәлил. “Җырларым”, “Ана бәйрәме”, “Соңгы җыр”, “Кызыл ромашка”, “Кошчык”, “Ышанма”, “Бер үгет”, “Дуска” шигырьләре, “Сандугач һәм чишмә” балладасы.
	4.16	Ф.Кәрим. “Ант”, “Ватаным өчен”, “Сөйләр сүзләр бик күп алар”, “Бездә яздыр”, “Сибәли дә сибәли”, “Теләк”, “Газиз әнкәй”, “Кыр казы” шигырьләре.
	4.17	Х.Туфан. “Кайсыгызның кулы җылы?”, “Киек казлар”, “Илдә ниләр бар икән?” шигырьләре.
	4.18	С.Хәким. “Бу кырлар, бу үзәннәрдә...”, “Әнкәй” шигырьләре.
	4.19	Ә.Еники. “Кем җырлады?”, “Әйтелмәгән васыять”, “Бала” хикәяләре.
	4.20	Ф.Хөсни. “Йөзек кашы” повесте.
	4.21	Г.Бәширов. “Туган ягым – яшел бишек” романы (өзекләр).
	4.22	М.Мәһдиев. “Без – кырык беренче ел балалары”, “Бәхилләшү” повестьлары.
	4.23	А.Гыйләҗев. “Җомга көн, кич белән”, “Язгы кәрваннар” повестьлары.
	4.24	Т.Миңнуллин. “Әлдермештән Әлмәндәр”, “Кулъяулык” драмалары.

Бүлек коды	Контроль бәяләү материалының коды	Контроль бәяләү материалларына нигезләнеп бәяләнүче берәмлекләрнең эчтәлеге
	4.25	Ш.Хөсәенов. “Әни килде” драмасы.
	4.26	Ф.Яруллин. “Җилкәннәр җилдә сынала” повесте.
	4.27	Г.Сабитов. “Тәүге соклану” хикәясе.
	4.28	Ф.Садриев. “Таң җиле” романы (өзекләр).
	4.29	Г.Гыйльманов. “Язмышның туган көне” хикәясе.
	4.30	И.Юзеев. “Өчәү чыктык ерак юлга”, “Калдыр, аккош, каурыеңны”, “Гашыйклар тавы” әсәрләре.
	4.31	Р.Фәйзуллин. “Якты моң”, “Җаныңның ваклыгын...”, “Онытма син!”, “Биеклек”, “Мин сиңа йомшак таң җиле...” шигырьләре.
	4.32	М.Әгъләмов. “Учак урыннары”, “Сабантуй”, “Каеннар булсаң иде”, “Без” шигырьләре.
	4.33	Зөлфәт. “Тылсым”, “Дүрт җыр”, “Бул гына” шигырьләре.
	4.34	З.Хәким. “Телсез Күке” драмасы.

II БҮЛЕК. Татар әдәбиятыннан дәүләт йомгаклау аттестациясе эшендә тикшерелә торган әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр исемлеге

Таләпнең Коды	Татар әдәбиятыннан дәүләт йомгаклау аттестациясе эшендә тикшерелә торган әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр
1	***Белергә / аңларга***
1.1	Сүз сәнгате буларак матур әдәбиятның үзенчәлекләрен.
1.2	Тәкъдим ителгән әсәрләрнең эчтәлеген.
1.3	Тәкъдим ителгән авторларның кыскача иҗат биографиясен.
1.4	Урта гасыр татар әдәбиятындагы төп әдәби-тарихи чорларны.
1.6	Төп теоретик төшенчәләрне.
2	***Эшли белергә***
2.1.	Әсәрнең эчтәлеген аңлата белергә.
2.2.	Әдәби әсәрне анализлый белергә: әдәби текстның мәгънәви өлешләрен аерып алырга, әсәрнең темасын, идеясен, автор

Таләпнең Коды	Татар әдәбиятыннан дәүләт йомгаклау аттестациясе эшендә тикшерелә торган әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр
	күтәргән проблемаларны дөрес билгеләргә, геройга характеристика бирергә, әсәрнең сюжет-композиция үзенчәлекләрен, әсәрдә кулланылган тел-сурәтләү чараларын билгеләргә.
2.3.	Тәкъдим ителгән әсәрне шул чор әдәби процессы белән бәйләнештә ачыклый, билгели алырга, әдәби факт һәм күренешләрне чагыштыра белергә.
2.4.	Әдәби текстка төр һәм жанр үзенчәлекләреннән чыгып анализ ясый белергә.
2.5.	Әсәрдә автор позициясен, автор стиленең үзенчәлеген, кулланылган тел-сурәтләү чараларының төрләрен, функцияләрен, әдәби алымнарны билгели алырга.
2.6.	Үз мөнәсәбәтен нигезле итеп дәлилли алырга.
2.7.	Укылган әсәргә карата үз мөнәсәбәтен язма формада бирә алырга.
3	***Алган белем һәм күнекмәләрне гамәли эштә һәм көндәлек тормышта куллану***
3.1.	Татар теленең әдәби нормаларына таянып, эзлекле текст язарга.
3.2.	Әңгәмә һәм бәхәсләрдә катнашырга.